СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 294 от 13.11.2024

На № __________ от _____________

# КАРАР

«Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмә» 2018 елның 09 апрелендәге 208 номерлы Саба муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәисләренең урынбасарларының, аудиторларының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 25 сентябрендәге 829 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР КЫЛДЫ:

**1.** «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Саба муниципаль районы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмә» 2018 елның 09 апрелендәге 208 номерлы Саба муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.** 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладын 13 990 сум күләмендә расларга.»;

**1.2.** 1 нче кушымтаны яңа редакциядә әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә бәян итәргә.

**2.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының җирле үзидарә органнарына, әлеге карар нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, 2025 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә булган яңа штат расписаниеләрен расларга.

**3.** Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

**4.** Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**5.** Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының http://pravo.tatarstan.ru рәсми хокукый мәгълүмат порталында рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

Саба муниципаль районы
Башлыгы Р. Н. Миннеханов

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Советының
2024 елның 13 ноябрендәге 294
номерлы карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башлыгының, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башлыгы урынбасарының, җирле үзидарәнең Саба муниципаль районында даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Контроль-хисап палатасы Рәисенең акчалата бүләкләү күләмнәре**

| Вазыйфалар исемнәре | Акчалата бүләкләү күләмнәре (сумнарда) |
|---|---|
| Муниципаль район Башлыгы | 37 036 |
| Муниципаль район Башлыгы урынбасары | 33 333 |
| Депутатлар | 18 162 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары | 15 432 |
| Муниципаль районның Контроль-хисап палатасы Рәисе | 33 333 |